Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Чарлы авыл җирлеге Советы

КАРАР

20 ноябрь 2020 ел №11

«Җир салымы турында» Чарлы авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 ноябрендәге 30 номерлы карарының 4 пункты үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Чарлы авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» Чарлы авыл җирлеге Советының 2013 елның ноябрендәге 30 номерлы карарының 4 пункты (Чарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 31 номерлы, 2015 елның 29 маендагы 24 номерлы, 2015 елның 25ноябрендәге 13 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 9 номерлы, 2018 елның 7 ноябрендәге 24 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 29 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 30 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 20 номерлы, 2020 елның 28 гыйнварындагы 1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Чарлы авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер айдан соң үз көченә керә.

Чарлы авыл җирлеге
башлыгы: Э.Н.Козлов